Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең
Түбән Кенә авылында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» октябрь 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елда гражданнар җыены билгеләгән мәсьәләләрне:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Зеленая урамы буенча юлларны ремонтлау);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (карт агачларны кисү)

үтәү барышында экономияләнгән 174465 (йөз җитмеш дүрт мең дүрт йөз алтмыш биш) сум 10 тиеннән акчаны

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Ю.Гагарина, Новая урамнары буенча юлларны ремонтлау)өчен файдаланырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Карадуган авыл җирлеге башлыгы Ш.В.Низамиев